**РАСЛЫЙМ**

**Россия ислам институты ректоры**

**Р.М. Мөхәммәтшин**

______________________

# Дини уку йортлары студентлары арасында республикакүләм татарча вәгазь укучылар бәйгесенең нигезләмәсе

## I. Гомуми нигезләре

1.1. Республикакүләм татарча вәгазь укучылар бәйгесе Татарстан урта һөнәри һәм югары мөселман уку йортлары студентлары арасында Россия ислам институты инициативасы һәм ярдәме белән «Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы» кысаларында уздырыла.

1.2. Бәйге татар телен, мәдәниятен үстерү өчен өстәмә шартлар тудыру, яшь буында телне, рухи мирасны, ислам дине кануннарын өйрәнүгә кызыксыну уяту, тел һәм дин өлкәсендәге белем һәм күнекмәләрне камилләштерүне күздә тота.

1.3. Бәйгенең максатлары:

- студентларда телне һәм ислам динен өйрәнүгә кызыксыну уяту, аңа хөрмәт тәрбияләү;
- милли үзаң формалаштыруга ярдәм итү, сөйләм культурасы тәрбияләү;
- татар телендә вәгазь укучы талантлы яшьләрне барлау;
- татар мәдәниятен, рухи мирасны өйрәнүне пропагандалау;
- татар телендә вәгазь уку традицияләрен яңарту, дәвам итү һәм үстерү;
- яшь буында ислам диненә хөрмәт тәрбияләү.

1.4. Бәйгедә Татарстан Республикасы урта һөнәри һәм югары мөселман уку йортларының көндезге бүлегендә белем алучы студентлар катнаша ала.

1.5. Бәйгегә чыгышлар видео форматында җибәрелә.

1.6. Бәйгене оештыручылар: Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният, ислам теологиясе кафедралары.

## II. Бәйге эшләренең эчтәлегенә һәм формасына таләпләр

2.1. Бәйге эшләренең эчтәлегенә һәм формасына түбәндәге гомуми таләпләр куела:

- чыгышлар традицион формада башкарылырга, яхшы сыйфатлы булырга тиеш; тавышны һәм видеоматериалны өстәмә эшкәртү рөхсәт ителми;
- тулысынча яздырылмаган видеоматериал конкурска кабул ителми;
- бәйгегә җибәрәсе чыгышны башыннан алып ахырына кадәр видеокамераны сүндермичә һәм туктатмыйча төшерергә кирәк;
- видеоязма 7-10 минуттан да артмаска тиеш;
- видеофайллар AVI, MPG4, MOV (берсен сайлап алырга) форматларында җибәрелә.
- вәгазь укучының киеме дини кануннарга туры килергә тиеш.

## III. Бәйгене оештыру һәм уздыру

3.1. Бәйге ике этапта үткәрелә:

I этапта конкурсантлардан чыгышларының видеоязмалары кабул ителә (2022 елның 11 декабренә кадәр).

II этапта жюри әгъзалары тарафыннан әлеге чыгышларга бәя бирелә (2022 елның 17 декабренә кадәр).

Бәйге нәтиҗәләре Россия ислам институтының рәсми сайтында урнаштырылачак.

3.2. Вәгазь темасы – ирекле.

3.3. Әлеге чарада катнашу өчен, видеоязманы, кушымтада күрсәтелгән форманы тутырып, **2022 елның 11 декабренә кадәр** riitatkafedra@mail.ru адресына җибәрергә кирәк. Бәйге эшләрен шулай ук Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт, Россия ислам институты, татар теле һәм милли мәдәният кафедрасына (икенче кат, 222нче бүлмә) да тапшырырга мөмкин. Тел. 8(843) 277-68-26.

3.4. Җиңүче, призлы урын алучыларга истәлекле бүләкләр тапшырыла. Һәр катнашучыга электрон сертификат бирелә.

## Кушымта

| Уку йорты | Фамилия, исем, әтисенең исеме | Телефон | Электрон адрес | Вәгазь темасы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |